Республика Татарстан
Кукморский Муниципальный район
СОВЕТ НЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422136, Республика Татарстан, Кукморский район,
п. Ныртинского совхоза, ул. Школьная, д.7
тел.: 8(84364) 39-2-52
эл. почта: Nirt.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР

31 май 2025 ел № 11

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезләмәләренә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законнарга, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү ТӘРТИБЕ (1 нче кушымта);

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Нырты авыл җирлеге
башлыгы Кутдусов Т.А.

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710

Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советының 2025 елның 31 маендагы 11 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү**
**ТӘРТИБЕ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау тәртибе, аны исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә урнашкан милекчесез яисә милекчесе билгесез булган күчемсез мөлкәткә йә милекчесе милек хокукыннан баш тарткан мөлкәткә кагыла.

1.3. Күчемсез мөлкәт объектларын хуҗасыз дип тану, хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә кую һәм муниципаль милеккә кабул итү өчен документлар рәсмиләштерүне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – җирлек Башкарма комитеты) әлеге Тәртип һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, башка норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын ачыклауның, ачыкланган хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль милек хокукын рәсмиләштерүнең төп максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- файдаланылмый торган мөлкәтне ирекле гражданнар әйләнешенә кертү;

- мөлкәтне нормаль һәм имин техник эксплуатацияләүне тәэмин итү;

- муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм тиешле торышы;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы

нигезендә билгеләнгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

1.5. Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган хуҗасыз күчемсез мөлкәтне муниципаль милеккә кабул итү мәсьәләләре Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән җайга салына.

## 2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау тәртибе, аны исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

2.1. Хуҗасызлык билгеләре булган күчемсез мөлкәт турында мәгълүматлар түбәндәгечә килергә мөмкин:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, прокуратурадан;

- инвентаризация үткәрү нәтиҗәсендә;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең инженерлык инфраструктурасы объектларында ремонт эшләре үткәргәндә;

- юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;

- башка ысуллар белән.

2.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын ачыклау эшләрен оештыру Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге башлыгы (алга таба - җирлек башлыгы) яисә җирлек башлыгы вәкаләт биргән зат тарафыннан хуҗасызлык билгеләре булган күчемсез мөлкәт турында кергән белешмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Ачыкланган хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү җирлек Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объекты турында мәгълүмат алган көннән алып 10 эш көне эчендә җирлек башлыгы яисә җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат, кергән мәгълүматны, 1 нче кушымтада каралган форма буенча хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау буенча АКТ төзеп, объект урнашкан урынга барып тикшерә.

2.5. Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау акты төзелгәннән соң, җирлек Башкарма комитеты йә җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат 10 эш көне эчендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны төгәлләштерү һәм тулыландыру эшен башкара, күчемсез мөлкәт объектының милекчесе булмавын яисә аның милекчесе билгесез булуын, яисә милекчесе аңа милек хокукыннан баш тартуын раслый торган документлар җыя.

Күчемсез мөлкәт объектының милекчесе булмавын яисә аның милекчесе билгесез

булуын раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

- әлеге күчемсез мөлкәт объекты федераль мөлкәт, Россия Федерациясе субъекты мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт реестрларында исәпкә алынмаганлыгы турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән документлар;

- хокуклар Техник инвентаризация бюросы органнарында теркәлмәгән;

- күчемсез милеккә хокукларны теркәүне гамәлгә ашыручы тиешле дәүләт органнары (оешмалары) тарафыннан бирелгән әлеге күчемсез мөлкәт объектларына хокукларның алар тарафыннан теркәлмәвен раслый торган документлар;

- күчемсез мөлкәт объекты турында Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр.

2.6. Милекченең күчемсез мөлкәткә хокукларыннан баш тартуын раслый торган документ булып, милекченең күчемсез мөлкәт объектына милек хокукыннан баш тарту һәм әлеге мөлкәтне хуҗасыз буларак исәпкә куюга ризалыгы турында (милекче бу мөлкәткә милек хокукыннан баш тарткан очракта бирелә) нотариаль таныкланган гаризасы тора.

Милекче – юридик зат мөлкәткә милек хокукыннан баш тарткан очракта һәм милек хокукы теркәлмәгән очракта, җирлек башлыгы йә җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны сората яки ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре;

- юридик затның гамәлгә кую документларының күчермәләре, юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, салым түләүченең идентификация номеры.

Милекче – физик зат мөлкәткә милек хокукыннан баш тарткан очракта һәм милек хокукы теркәлмәгән очракта, җирлек Башкарма комитеты йә җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре;

сората:

- физик затны юридик зат төземичә эшмәкәр буларак теркәү турында белешмәләр;

- гражданның шәхесен раслый торган документ күчермәсе.

2.7. Күчемсез мөлкәт объектының милекчесе турында мәгълүмат алынган очракта, тиешле объектны хуҗасыз буларак исәпкә кую өчен документлар җыю эше туктатыла, бу хакта хуҗасыз күчемсез мөлкәт турында белешмәләр биргән затка хәбәр ителә.

2.8. Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, хуҗасыз күчемсез мөлкәт объекты турындагы белешмәләрне тикшерү чаралары тәмамланганнан соң 10 эш

көне эчендә җирлек Башкарма комитетының күчемсез мөлкәт объектын хуҗасыз дип тану һәм аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектлары реестрына (алга таба - Реестр) кертү турында карары чыгарыла.

2.9. Реестрны алып бару 2 нче кушымта белән расланган форма буенча җирлек Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.10. Күчемсез мөлкәт объектын хуҗасыз дип тану турында җирлек Башкарма комитеты карары кабул ителгән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, җирлек Башкарма комитеты Техник инвентаризация органнарында кадастр һәм техник паспортлар һәм планнар әзерләүгә заказ бирә. Техник инвентаризация үткәрү һәм кадастр һәм техник паспортлар әзерләү эшләре җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

2.11. Хуҗасызлык билгеләре булган мөлкәтне җимерү (югалту) куркынычын булдырмау, гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыра торган авария хәлләре килеп чыгу һәм алардан килгән зыяннарны бетерү максатларында (тормышны тәэмин итү объектларын, инженерлык инфраструктурасын һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә тоту өлешендә) ьирлек Башкарма комитеты әлеге мөлкәтнең сакланышын әлеге максатларга бүлеп бирелгән җирле бюджет акчалары исәбенә һәм чикләрендә тәэмин итә.

Ачыкланган хуҗасыз җылылык челтәрләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукы танылганчы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су түгүнең үзәкләштерелгән системаларының, шул исәптән, аларны эксплуатацияләү юлы белән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су чыгару тәэмин ителә торган суүткәргеч һәм канализация челтәрләренең ачыкланган хуҗасыз объектларын, шул исәптән суүткәргеч һәм канализация челтәрләрен күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукы танылганчыга кадәр яисә Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә мондый объектларны калдырган милекче аларны биләүгә, файдалануга һәм алар белән эш итүгә алганчыга кадәр карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.12. Ачыкланган күчемсез мөлкәт объектын исәпкә кую Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгы нигезендә җирлек Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.13. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектын исәпкә куйган көннән соң бер ел узгач, җирлек Башкарма комитеты мондый объектка муниципаль милек хокукын тану турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итә.

Ачыкланган электр челтәре хуҗалыгы объектларын һәм башка линия объектларын исәпкә кую «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирлек башлыгы яки башлык вәкаләт биргән зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Линия объектларына карата хуҗасыз күчемсез әйбер исәпкә куелган көннән алып

кыскартылган срок өч ай билгеләнгән, шул вакыт узгач, җирлек башлыгы йә җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат муниципаль милек хокукын тану турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итә ала.

2.14. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль милеккә кабул итү 2.12 пунктында күрсәтелгән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган законлы көченә кергән суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.15. Күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органның муниципаль милек хокукын дәүләт теркәвенә алу чаралары муниципаль милек хокукын тану турындагы суд карары законлы көченә кергән вакыттан алып 10 эш көне эчендә җирлек Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.16. Муниципаль милек хокукы теркәлгәннән соң, җирлек Башкарма комитеты 10 эш көне эчендә объектны Реестрдан төшерү һәм муниципаль мөлкәт реестрына кертү буенча чаралар үткәрә.

2.17. Муниципаль милек хокукы теркәлгәннән соң, Башкарма комитет әлеге күчемсез милек объектлары астындагы җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча чаралар үткәрә.

Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау**
**АКТЫ**

«__»________________ ел .______

Мин, ____________________________________________________________

____________________________________________________________________

(ФИО һәм вазыйфасы күрсәтелә)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

кергән гариза (мөрәҗәгать) нигезендә ______________________

(керү номеры ____ ) хуҗасызлык билгеләре булган күчемсез милек объектын тикшереп чыктым.

Мөлкәт исеме ____________________________________________________

Мөлкәтнең урнашу урыны ______________________________________________

Мөлкәткә кыскача характеристика _________________________________________

Милекне хуҗасыз милеккә кертү билгеләре ____________

____________________________________________________________________

Милекнең элеккеге хуҗасы ______________________________________________

Милек кайчаннан бирле хуҗасыз ___________________________________

Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибенә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары**
**РЕЕСТРЫ**

| N т/б | Объектның исеме | Объектның урнашу урыны | Объектка кыскача характеристика | Объектны хуҗасыз дип тану турында администрация карары номеры, датасы | Теркәү органында исәпкә кую датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |